**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 18 июнендәге 2550 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 30 ноябрендәге 3768 номерлы «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәреш кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» федераль законы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» карары белән, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү максатларында **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 30 ноябрендәге 3768 номерлы «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәреш кертеп, 2.5.1 пунктның «8)» пунктчасына «2023 елның 2 октябрендәге 509-ФЗ номерлы «Күчемсез милек объектларының аерым төрләренә хокукларны рәсмиләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон нигезендә аларга карата дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яисә) хокукларны дәүләт теркәвенә алу гамәлгә ашырылмый торган капиталь төзелеш объектын кертүдән тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р. Г.Гафаров**